3. объяснить правила игры, рассказать о том, что получится в результате, тем самым, вызвать у обучаемых положительные эмоции, интерес, стремление как можно быстрее включиться в игру;
4. постоянно пополнять перечень игр, изучать накопленный опыт их применения в системе обучения нашей страны и за рубежом.

Кроме того, всестороннее исследование игры как средства формирования и развития коммуникативных умений обучаемых, анализ литературы позволяют сделать вывод, что учебная игра представляет собой средство оптимизации учебного процесса в целом и интеллектуальной активности в частности. Эффективность формирования и развития коммуникативных умений по иностранному языку во многом зависит от целесообразности использования их на занятии, направленности их содержания на решение задач, связанных с овладением иностранным языком, последовательности использования различных видов игры в рамках традиционного обучения. Существует прямая зависимость между системой применения учебных игр и ускорением процесса формирования и развития умений, активностью обучаемых на занятии. Поэтому методически грамотное применение игр делает процесс обучения более интенсивным по сравнению с традиционной системой обучения.

Однако хотелось бы подчеркнуть, что игра – это лишь оболочка, форма, содержанием и назначением которой должно быть учение, в нашем случае – овладение видами речевой деятельности как средствами общения.

**Литература**


1. Воронов В.В. Педагогика школы в двух словах. – М.: Педагогическое общество России, 1999. –192 с.
2. Деркач А.А., Щербак С.Ф. Педагогическая эвристика. Искусство овладения иностранным языком. – М.: Педагогика, 1991. – 224 с.
3. Комарова Ю.А. Использование учебных игр в процессе обучения иностранным языкам. Методическое пособие: Обучение иностранным языкам в школе и вузе. – СПб: КАРО, 2001.– С. 111-119
4. Советова Е.В. Эффективные образовательные технологии. – Ростов н/Д: Феникс, 2007.– 285с.



**УДК 82-2**



**Ф.Х. Миннуллина**

*Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ, г. Казань, Россия*


# ОТРАЖЕНИЕ ЖИЗНЕННЫХ ПРОТИВОРЕЧИЙ В ДРАМАХ З.ХАКИМА (НА ПРИМЕРЕ ПЬЕС “ТАИНСТВЕННАЯ ДЕВУШКА” И “СЛУЧАЙНАЯ ВСТРЕЧА”)


***Аннотация.*** *Статья посвящена изучению драм З. Хакима «Тайнственная девушка» и «Случайная встреча». В пьесах жизненные противоречия раскрываются сквозь сложные формы связей личности с жизнью.*



***Ключевые слова:*** *драма, З. Хаким, конфликт, герой, противоречия, пьеса.*



**F.Kh. Minnullina**

*G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art, Tatarstan Academy of Sciences, Kazan, Russia*


# THE REFLECTION OF LIFE CONTRADICTIONS IN Z. KHAKIM’S DRAMAS (ON THE EXAMPLE OF HIS PLAYS “THE MYSTERIOUS GIRL” AND “ACCIDENTAL MEETING”)


***Abstract:*** *The article is devoted to the study of Z. Khakim’s dramas. In the plays “The Mysterious Girl” and “Accidental Meeting”, lıfe contradictions are revealed through complex forms of personality’s connections with lıfe.*



***Key words:*** *drama, Z. Khakim, conflict, character, contradictions, play.*


# ХӘКИМ ДРАМАЛАРЫНДА ЗАМАН КАРШЫЛЫГЫ («СӘЕР КЫЗ», «ОЧРАКЛЫ ОЧРАШУ» ПЬЕСАЛАРЫ МИСАЛЫНДА)

XX йөз ахырында башланып киткән иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр әдәбиятка яңадан-яңа тема һәм проблемалар алып килә. Шуларга бәйле рәвештә, соңгы елларда иҗат ителгән драма әсәрләре образлар системасы, идея-эстетик үзенчәлекләре ягыннан берникадәр үзгәреш кичерә. XX гасырның икенче яртысында туган яңалыклар XXI йөз башы татар драматургиясендә дә дәвам итә. Әлеге яңалыклар тема-жанрлар төрлелегендә дә, сурәтләү формаларында да чагылыш таба. Сәхнә әдәбиятындагы сыйфат үзгәрешләре Т Миңнуллин, Р Хәмид, Ф Бәйрәмова, Ю Сафиуллин, З Хәким. Г Каюмов, Д Салихов, Р Сәгъди, М Гыйләҗев, Р Зәйдулла, һ.б. иҗаты белән бәйле. Җәмгыятьтәге үзгәрешләр нәтиҗәсендә сәхнә әдәбиятында күзәтелгән яңалыкларның берсе – тематик төрлелек. Мәсәлән, татар драматургиясенең күренекле вәкилләреннән берсе булган З. Хәким пьесаларында төрле характердагы изүләргә каршы көрәш, протест, ягъни оппозиҹион караш ачык булып күзгә ташлана. Әдипнең яңа форма, стиль, образлар системасы белән аерылып торган «Су төбендә сөйгәнем», «Кишер басуы», «Күрәзәче», «Шайтан куентыгы», «Чапты атым Казанга», «Телсез күке», «Бит», «Гасыр моңы»кебек әсәрләрендә сүз тоталитар система турында гына түгел, ә яшәешебездә чәчәк аткан мәрхәмәтсезлек, кеше шәхесен изгән бюрократик идарәчеләр хакында да бара. Драматургның «Сәер кыз», «Очраклы очрашу» **драмалары** да фәлсәфи-интеллектуаль характерда.

Пьесаларда әхлакый кыйммәтләрнең кимүе, яшәешкә эчкечелек, әхлакый тотнаксызлык, күңел катылыгы һ.б. тискәре сыйфатларның үтеп керүе тасвирлана. Аларда геройлар язмышы тирән конфликтлы драматик вакыйгалар аша яктыртыла. Җәмгыятьтә шәхеснең роле билгеләнә, кешелеклелек кыйммәтләре, бәхет төшенчәсен ни рәвешле аңлаулары, яшәү мәгънәсе нидән гыйбарәт булуы чагылыш таба. Тормыш-яшәештәге үзгәрешләр, аеруча яшьләрнең эш-гамәлендә һәм характер сыйфатларында чагыла. «Очраклы очрашу» драмасының үзәгендә, мәсәлән, кеше һәм җәмгыять каршылыгы әхлакый проблемалар белән тыгыз бәйләнештә гәүдәләндерелә. Авторны яшь буынның үзара һәм шул ук вакытта олыларга карата булган мөнәсәбәтләре, дуслык, мәхәббәт, гаилә кору, җәмгыятьтә үз урыннарын, шәхси бәхетен табу мәсьәләләре кызыксындыра. Драматургны яшәешкә, яшьләр арасына үтеп кергән наркотик кебек куркынычның, эчкечелек, әхлаксызлык кебек яман гадәтләрнең артуы борчый. Пьесаның төп герое Ләйләнең һәр сүзе, гамәлләре, мәхәббәт, гаилә мәсьәләсенә карата булган уй-фикерләре, теләкләре автор фикерен тирәнәйтә. Медиҹина университетына яңа гына укырга кереп эшкә урнашкан, саф мәхәббәт, бәхетле гаилә турында хыялланган кыз, үз мәнфәгатьләрен генә кайгырткан, наркотикларга бирелгән Алмаз тарафыннан алдануына карамастан, кешеләргә булган ышанычын югалтмый. Өмет-хыяллары челпәрәмә килгән Ләйлә бу катлаулы, “аяусыз” тормышта яңа сукмак таба – тормыш мәгънәсен башкаларга файдалы булуда күрә. Бәхетле яшәү, тормыш кыенлыкларын җиңү өчен парлы булу, кем беләндер үзара аңлашып, бер-береңә ярдәмләшеп, иңне-иңгә куеп янәшә бару кирәк, ә яшәештә ике капма-каршы чик бар: матурлык һәм файда, мәхәббәт һәм хыянәт, өмет һәм чарасызлык, ышаныч һәм ялгызлык. Беренче урынга автор мәхәббәтне чыгара. Авылдан килеп үз көнен үзе күргән, саф күңелле Илсур Ләйләне чын күңелдән якын итә, ярата. Яшь парлар бер теләк, бер омтылыш белән яшиләр: алар **бәхет**ле булырга телиләр. Димәк, пьесаның геройлары өчен бәхет – ул уңайлы йорт, дус гаилә, яраткан эш һәм ***иң кадерле кешеләреңне ярату, алар белән бергә булу***. Әйтергә кирәк, Алмаз образы ярдәмендә автор мәхәббәткә, дуслыкка җавапсыз карау, наркомания, эчкечелек кебек тискәре күренешләргә каршы тора алмауныңзур югалтуларга, ялгызлыкка, бәхетсезлеккә китерүен күрсәтә. Алмазның рухи түбәнлеккә төшүе, соңыннан үз-үзен һәм тормыштагы урынын аңларга омтылуы, тугры юлга басуы психологик яктан уңышлы мотивлаштырыла. Герой эволюҹиясе хис-кичерешләрнең, эш-гамәлләрнең каршылыклары аша бирелә. Гомумән, З. Хәким иҗатында милләтнең киләчәге булган яшьләр мәсьәләсе зур урын алып тора. Мәсәлән, «Очраклы очрашу» драмасында сурәтләнгән Әлфидә образы аша драматург яшьләр арасында киң таралган әхлаксыз күренешләрнең артуын, «саф» мәхәббәтнең «ирекле» мәхәббәткә алмашынуын тасвирлый. Кыз үзенең бу адымын җәмгыятьтәге тәртипләр, тормыш кыенлыгы, дөньядагы гаделсезлекләр белән бәйле булуын ассызыклый. Күренә ки, драмада яшь буынның ике тибы аерылып чыга. Бер төркеме әхлакый кыйммәтләрне саклап яшәргә омтылучы геройлар итеп сурәтләнсә (Ләйлә, Илсур), икенче төркем яшәү мәгънәсен соңлап аңлаган, тормыш баткагына чумган, ялгыш юлдан киткән геройларны үз эченә ала (Алмаз, Әлфидә). Драматург шәхес ялгызлыгын, аның чынбарлык белән трагик каршылыгын Алмазның әнисе Нурдидә аша да күрсәтә. Ләйләнең «Бик ялгыз кеше син, якын кешеләр белән аралашу җылысы җитми сиңа», - дип әйтүе шуны раслый [2, с.351]. Ике бала үстереп, аларны чын кеше итә алмадым дип борчылаана. Аның эчке дөньясы драматик хисләр белән тулы. Шуңа да карамастан, ана балаларына булган ышанычын югалтмый. Автор Нурдидәнең олы улы Флүснең айлар буе әнисенә шалтыратмавы, туган йортына фатир бүлешергә генә кайтулары аша игътибарын кешелексезлек, шәфкатьсезлек, рухи ярлылык мәсьәләсенә юнәлтә. Буыннар арасындагы аңлашылмаучанлык, хаклыкны табарга тырышу әхлак призмасы аша үткәрелә.

Реалистик сюжет сызыгы күп каршылыклар ярдәмендә җәмгыятьтәге бик күп проблемаларны ача: битарафлык,комсызлык (Флүс, Алмаз), эчкечелек (Алмаз), азгынлык (Әлфидә, Алмаз). Җыеп әйткәндә, әдип бер гаилә эчендәге катлаулы мөнәсәбәтләрне сурәтләп, чорның гаять каршылыклы якларын ача. Рухи һәм матди кыйммәтләргә мөнәсәбәт характерларның асылын билгели. Яшьлек, мәхәббәт, намус кебек мөһим мәсьәләләр З. Хәкимнең «Сәер кыз» драмасында да күтәрелә. Ул «... интеллектуаль эчтәлекле әсәр булып тора һәм анда сәнгатьнең асылы, тормыштагы әһәмияте, сәнгать кешеләре турында җитди бәхәс бара» [1]. Яшь кыз Дилбәрнең авыл клубын бизәргә килгән рәссам Мөхтәр белән сәнгатьтәге матурлык турындагы бәхәсе тормыштагы, яшәештәге матурлык дәрәҗәсенә үсә. Мөхтәр үзен матурлык тудыручы, шуңа күрә дә үз эшен кешеләргә кирәк дип саный. Рәссам фикеренчә, матурлыкны күрә белү кешенең күңелебелән бәйле. Тик «иҗат, сәнгать, матурлык төшенчәләре кеше шәхесе белән бәйле, ә кешенең исә матур әйберне үзенеке генә итәсе килә» [1]. Дилбәр белән Әсәд, Рания белән Әүхәд арасындагы шәхси мөнәсәбәтләр дә шуны раслый. Ранияның мәсәлән, эшмәкәр Әүхәдтән аерылуындатөп сәбәп – ирнең хатынын үз шәхси милке итеп санавында. Армиядән отпускка кайткан, Дилбәрне яратып йөргән Әсәд тә кызны вәгъдәсендә тормауда, аны рәссам Мөхтәр белән аралашуда, хыянәт итүдә гаепли, гомумән, үз-үзен тотышы, кызга шәхси милке итеп каравы беләнүзенең түбән җанлы, тупас, тәрбиясезкеше булуын күрсәтә. З. Хәким үзенең геройларын “җиде юл” чатына алып килә һәм шул урында ул аларның кешелек сыйфатларын сыный һәм бу критерийлар шактый ук катгый булып чыга. Аның карашынча, башкаларны санламыйча, гел үзеңне генә кайгыртудан килгән **бәхет**- хурлык тәнкыйтьләнергә тиеш. Драматург Рания белән Әүхәд, Дилбәр белән Әсад образлары аша бик мөһим бер проблеманы ачыклый: бәхетле булу өчен «пар канат» булу гына җитми, гаилә тормышын уңышлы кора белү, бер-береңне хөрмәт итеп, аңлап яшәү дә кирәк. Моның өчен җәмгыятьтә сәламәт әхлакый кануннар, кешелекле принципплар яшәргә тиеш. Дилбәр, Рания образлары ярдәмендә авторның мәхәббәт концепциясендә ярату, шатлык, бәхет белән бергә, борчу китерүе турындагы фикере яңгырап кына калмый, ә соңгысының вакыйга-күренешләрдә өстенлек итүе дә билгеләнә.

Драмада Дилбәр хыял белән яшәүче, тормышта бәхетен табарга омтылган авыл кызы буларак сурәтләнә. Күренә ки, Дилбәр башкаларгаохшамаган матурлык эзләүче, сизгер, нечкә күңелле кеше. Шуңа күрә дә кешеләр аны «сәер», үзгә буларак бәялиләр. Яшәештә матурлыкны гына күрергә теләгән кызны әхлакый-социаль проблемалар борчый. Кыз үзенең хыял–омтылышлары белән шәхес иреген яклый. Табигать һәм сәнгать матурлыгын күрә белүче бу герой кешеләр арасындагы әхлаксызлыкны, гаделсезлекне, ваемсызлыкны кага. Рания белән Дилбәрнең бүгенге яшәешкә, җәмгыятькә бәяләре, уй-фикерләре тирән мәгънәгә ия. Алар фикеренчә, хезмәт, намус, батырлык, дуслык, тугрылык кебек сыйфатлар гына кешене чын кеше итеп таныта. Бу бәйләнеш – аларның яшәү мәгънәсе, эчке дөньяларының матурлыгы, сафлыгы.

Җыеп әйткәндә, З. Хәким «Сәер кыз», «Очраклы очрашу» драмаларында яшьләрнең хис-кичерешләрен бәяләү аша яшәү мәгънәсе турындагы бәхәсне үстерә. Әсәрләрдә б**әхет исә** кешенең җиһандагы яшәеш, тормыш фәлсәфәсе белән тыгыз бәйләнештә торуын ассызыклый. Заман кешеләренең яшәү рәвешенә, уй-хыялларына, әхлакый сыйфатларына, рухи дөньяларындагы үзгәрешләргә игътибар итә.Төп сюжет сызыгындагы каршылык ачыклануга, яшәешнең бер кануны укучыга мәгълүм була: кешеләртөрле —кайберәүләр үз файдасы өчен яши, ә кемнәрдер матурлык эзләп, җәмгыятьтәге көнитеш тәртипләрен кабул итмичә, каршылыкка керә.

**Әдәбият**


1. Закирҗанов Ә.М. Эзләнү юлында (Зөлфәт Хәкимнең соңгы еллар иҗатына бер караш) // kpfu.ru/staff_files/F1386649134/З Хаким.doc (дата обращения: 25. 09. 2017).
2. Хәким З. Кайда син, Атилла? – Казан: Татар.кит.нәшр., 2013. – 431 б.



**УДК 811.1/.8**



**О.А. Морозова**

*Казанский федеральный университет, г. Елабуга, Россия*


# ПРОБЛЕМЫ ЛЕКСИКОГРАФИЧЕСКОЙ ФИКСАЦИИ НЕКОДИФИЦИРОВАННОЙ СОСТАВЛЯЮЩЕЙ


***Аннотация.*** *В статье излагаются основные проблемы составления словарей некодифицированной составляющей нефтяного профессионального языка. Лексикографы не оказывают достаточного внимания*